# Кунакка чакыру







Сорауларны укыйбыз,җавап бирәбез.

“А”

-Төлке белән Торна ничек яшиләр?

-Төлке кемне кунакка чакыра?

-Ул нәрсә пешерә?

-Ботканы кем ашый?

“Б”

-Торна кемне кунакка чакыра?

-Ул нәрсә пешерә?

-Торна нәрсә ди?

-Ни өчен Төлке белән Торнаның дуслыгы бетә?

## КУНАКТА ҮЗЕҢНЕ ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

- **Үзеңне тыныч тотарга кирәк. Кычкырып сөйләшергә ярамый.**
- **Матур итеп,чиста-пөхтә киенеп килергә кирәк. Ямьсез киенеп кунакка бармыйлар.**
- **Хуҗалар белән әдәпле итеп исәнләшәләр,матур итеп күчтәнәчләрне, бүләкләрне тапшыралар.**
- **Өстәл артында алдыңа куелган тәлинкәдән генә ашыйлар. Кеше алдына үрелеп утырмыйлар.**
- **Берәр әйбер кирәк булса, зинһар өчен  алып бирегез дип сорарга кирәк.**
- **Өстәл артыннан кузгалганда рәхмәт әйтә белергә кирәк.**
- **Өйгә кайтканда хуҗаларга рәхмәт әйтеп, саубуллашып кайтып китәргә кирәк.**

# Тылсымлы сүзләр

- Исәнмесез.
- Хәерле көн.
- Рәхим итегез.
- Зинһар өчен.
- Рәхмәт.
- Таныш булыгыз.
- Гафу итегез.
- Кичерегез.
- Керергә мөмкинме?
- Туган көнең белән.
- Ашыгыз тәмле булсын.
- Безгә кунакка килегез.
- Сау булыгыз.
- Хәерле юл.



# МӘКАЛЬЛӘР

- Кунак ашы - кара каршы.
- Кунак булсаң - тыйнак бул.
- Кунакка барсаң, кунак көт.
- Яхшы ашка - кыстау кирәкми.

# Татар халык ашлары





# 3-2-1.

- 3 Ошады:
- 2 Ошамады:
- 1 Аңламадым:

# ӨЙ ЭШЕ

- ”Кунакта” дигән темага диалог язып килергә.